**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2024 елның «25» гыйнварыннан № 25

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр прейскурантын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәнең гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының муниципаль бюджет учреждениеләре тарафыннан түләүле һәм керем китерә торган башка хезмәтләр күрсәтү турындагы нигезләмәләрне раслау хакында» 2023 елның 29 декабрендәге 40-325 номерлы Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары нигезендә, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр күрсәтүне тәртипкә салу максатларында Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты карар бирә:

1. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр прейскурантын кушымта нигезендә расларга.

2. «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Яңа Чишмә балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган керем китерә торган эшчәнлек

турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 17 августындагы 221 номерлы карары (2022 елның 12 сентябрендәге 255 номерлыкарардагы үзгәрешләр белән ) үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Җитәкче Р.Р. Фасахов

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Башкарма комитетының
2024 елның «25» гыйнварындагы
25 номерлы карары белән
расланган

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Яңа Чишмә балалар сәнгать мәктәбе» муниципаль бюджет өстәмә белем бирү учреждениесе тарафыннан күрсәтелә торган түләүле хезмәтләр прейскуранты

| № т/б | Хезмәтләр исемлеге | Хезмәтнең бәясе, сумнарда | Хезмәт күрсәтү дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|
| Белем бирү хезмәтләре | | | |
| 1. | Хореография сәнгате | 1100 | Атнага 3 сәгать: |
| 2. | Музыкаль сәнгать | 1100 | Атнага 2 сәгать: |
| 3. | Сынлы сәнгать | 1100 | Атнага 3 сәгать: |
| Башка хезмәтләр | | | |
| 1. | «Беренче адымнар» иртә - эстетик үсеш | 600 | 1 ай (8 дәрес) |
| 2. | «Музыкаль кунак бүлмәсе» | 200 - 350 | 1 кешедән |
| 3. | «Талантлар салават күпере» иҗади остаханәсе | 200 - 350 | 1 кешедән |
| 4. | Фәнни – гамәли конференцияләр, киңәшмәләр, күргәзмәләр, концертлар һәм башка шундый чараларны оештыру һәм үткәрү | 200 - 350 | 1 кешедән |
| 5. | Белем бирү эшчәнлеге кысаларында башкарыла торган методик, мәгълүмати продукцияне керем китерә торган эшчәнлектән алынган акчалар исәбеннән гамәлгә ашыру | 100 - 300 | 1 кешедән |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 6. | Сәнгать, бизәү һәм дизайнерлык эшләрен башкару (эшнең күләменә һәм катлаулылыгына карап) | 1000 – 10000 | 1 кешедән |
| 7. | Учреждение китапханәсе күрсәтә торган түләүле хезмәтләр | 100 - 200 | 1 кешедән |
| 8. | Экскурсия, мәдәни - массакүләм хезмәтләр күрсәтү | 150 - 350 | 1 кешедән |
| 9. | Үзләре җитештергән товарлар белән сәүдә итү | 50 - 500 | 1 кешедән |
| 10. | Башка учреждениеләр һәм оешмалар (шул исәптән мәгариф оешмалары) эшчәнлегендә өлешләп катнашу | Тулай җыемның 10% ы | |